Министерство культуры Республики Татарстан
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

**ФИЛАРМОНИЯ**

Татарская государственная филармония имени Габдуллы Тукая
Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе

# Рәхмәт хаты

Хөрмәтле

Миләүшә Хәйруллина!

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе халкыбызның бөек җырчысы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакировның тууына 85 ел тулуга багышланган «Илһам Шакиров рояле» музыкаль марафонында катнашуыгыз өчен Сезгә тирән ихтирамын белдерә.

Күренекле җырчының кул җылысын, моңын, хисләрен сеңдергән уникаль рояльне Татар филармониясенә Илһам Шакировның варислары тапшырды. Рояль телләре музыкантлар кулын тойганда, җырчы турында хәтер яшәр!

**Габдулла Тукай исемендәге**
**Татар дәүләт филармониясе**
**директоры** **К. Н. Нуруллин**